# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№1** **22.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге составына керүче,
Беренче Май торак пунктында гражданнар
Җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Беренче май б., Югары (Верхняя) урамына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Беренче Май бистәсендә балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Беренче Май бистәсендә юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 174 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны 105 кеше

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашучы 105 кеше « РИЗА » позициясе өчен тавыш бирде; « КАРШЫ » позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге составына керүче Урманай авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә «Сез, 2020 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300

сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Беренче май б., Югары (Верхняя) урамына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Беренче Май бистәсендә балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;

- Беренче Май бистәсендә юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 15А й. (Башкарма комитет администрациясе бинасы);

-423311,ТР, Азнакай районы, Беренче Май бистәсе, Средняя ур., 14й. (Беренче Май бистәсе мәдәният йорты).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урманай авыл җирлеге Башлыгы: А.И.Закиров